Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның 16 феврале №6/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Татар Талкышы авыл җирлеге
Советының 05.06.2019 елның 59/1 номерлы
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы «Татар Талкышы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт
турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль закон нигезендә, Чистай шәһәр прокурорының 26.01.2026 ел, №020802-2026 Советның 05.06.2019 ел, №59/1 карарына протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Советының 05.06.2019 ел №62/1 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 13 маддәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10) «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;
5 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «гамәлдәге законнарда» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы М.М. Валиев